**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

"09" 09 2021 ел Яр Чаллы № 2634

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет төзү турында

Татарстан Республикасында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча ведомствоара совет утырышының 2021 елның 28 маендагы ЛФ-12-113 номерлы беркетмәсенең 1.4 пунктын үтәү йөзеннән, Тукай муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы ирекләләр берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм итү һәм ирекле ярәмчеләрләр хәрәкәтен үстерү максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет төзергә.
2. Расларга:
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет турында нигезләмәне (1 кушымта);
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет составын (2 кушымта).
3. Карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) һәм ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның "09" 09 [illegible] номерлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәмләр

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет (алга таба - совет) ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерүдә көчләрне туплау максатында җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, социаль юнәлештәге коммерциясез оешмаларның, ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) оешмаларының, башка кызыксынган оешмаларның килештерелгән эшчәнлеген тәэмин итүче Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы даими эшләүче консультатив орган булып тора.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасының башка хокукый актлары, Тукай муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Советның максаты һәм бурычлары

2.1. Советның максаты: ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсешендә көчләрне берләштерү, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының иҗтимагый ирекле ярдәмчеләр берләшмәләре эшчәнлеген координацияләү.

2.2. Советның бурычлары:

- Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының иҗтимагый берләшмәләр, социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар, ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) оешмалары һәм башка кызыксынган оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- социаль бурычларны хәл итүдә ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) оешмаларының һәм ирекле ярдәмчеләрнең ихтыяҗын тәэмин итә торган шартлар тудыру;
- ирекле ярдәмчелекне киңәйтү һәм ныгыту өчен, гамәлдәге оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итү һәм яңа ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) оешмалары барлыкка килү өчен шартлар тәэмин итү, аларның потенциалын күтәрүгә булышу;

- ирекле ярдәмчелек эшчәнлегенә методик, мәгълүмати, консультация ярдәме инфраструктурасын үстерү;

- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге чараларын үткәрүгә халыкны җәлеп итү механизмнарын эшләү;

- ирекле ярәмчелек (волонтерлык) өлкәсендә эшчәнлекне җайга салучы Тукай муниципаль районының хокукый актлары проектлары буенча фикер алышу. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән гамәлдәге чараларның нәтиҗәлелеге предметына кабул ителгән хокукый актларны һәм хокук куллану практикасын анализлау.

## 3. Советның хокуклары

4.1. Совет хокуклы:

4.1.1. Совет компетенциясенә карый торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының региональ башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кирәкле документлар һәм белешмәләр соратырга һәм алырга.

4.1.2. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсешендә көчләрне берләштерү максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар, ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) оешмалары һәм башка кызыксынган оешмалар вәкилләрен Совет утырышына чакырырга.

4.2. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) үсеше мәсьәләләре буенча дәүләт, муниципаль хакимият органнарына тәкъдимнәр тапшырырга.

## 4. Советныңэш тәртибе

4.1. Совет составына совет рәисе, совет рәисе урынбасары, секретарь, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген төп оештыручылар, ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) төркемнәре лидерлары, аның составына керү өчен язма рәвештә үз ризалыкларын белдергән иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, предприятиеләр керә.

4.2. Вазыйфасы буенча Совет рәисе булып Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары тора.

4.3. Совет составы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.4. Совет эшенә совет рәисе, ә ул югында аның кушуы буенча аның урынбасары җитәкчелек итә.

4.5. Совет утырышларны кирәк булган саен, кварталга кимендә бер тапкыр уздыра.

4.6. Совет рәисе үз вәкаләтләре кысаларында:

- совет утырышын үткәрү турында карар кабул итә, көн тәртибен билгели;

- совет кабул иткән карарларның үтәлешен тәэмин итә һәм контрольдә тота; совет әгъзаларына компетенциясе кысаларында йөкләмәләр бирә.

4.7. Совет эше аның утырышларында раслана торган планнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.8. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санныннан яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.9. Совет утырышына көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча материаллар совет әгъзалары тарафыннан аларның компетенциясе кысаларында әзерләнә. Материаллар совет секретаренә утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

4.10. Совет карарлары совет утырышында катнашучы совет әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, совет утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Совет карарлары тәкъдим итү характерына ия.

4.11. Совет утырышы беркетмәсенә совет утырышыннан соң 5 эш көне эчендә рәислек итүче һәм совет секретаре тарафыннан имза куела.

4.12. Совет утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

- совет утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

- совет утырышының расланган көн тәртибе;

- совет әгъзаларының һәм чакырылган башка затларның исемнәре һәм вазыйфалары;

- совет утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарлар.

4.13. Совет утырышлары беркетмәләре яисә алардан кирәкле өземтәләр Совет утырышы көненнән алып 5 эш көне эчендә совет секретаре тарафыннан йөкләмәләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затларга җибәрелә.

4.14. Совет эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне совет секретаре гамәлгә ашыра.

4.15. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башкара.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның “___” ___09___ ___ номерлы карарына 2 кушымта

**Тукай муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча совет составы**

| | |
|---|---|
| Бариев И.Ш. | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, эшче төркем рәисе; |
| Гәрәев И.Р. | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Нәҗипова Р.А. | - Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ директоры, комиссия секретаре. |

**Эшче төркем әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Ибраһимов А.С. | - Тукай муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Сәхбетдинов И.И. | - Тукай муниципаль районының «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ директоры; |
| Бариева Л.Ф. | - Татарстан Республикасы Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының Тукай районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сабирҗанов Г.Г. | - «Тукай үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча). |